СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карары**

**12 август 2024 ел** **№ 100**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2021 елның 23 апрелендәге 19 номерлы карары белән расланган (03.10.2022 ел №59, 25.10.2023 ел №82 үзгәрешләр белән) Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

а) 1 өлешнең 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"12) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;";

б) 20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"20) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үзбелдекле төзелгән корылманы сүтү турында карар кабул итү, үзбелдекле төзелгән корылманы сүтү яисә аны капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән иң чик параметрларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү";

в) түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:

"21) "Шәхси ярдәмче хуҗалык турында" 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче

хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру".

2) 12 статьяның 7 пунктында "Җирлек сайлау комиссиясе" сүзләрен "территориаль комиссия" сүзләренә алмаштырырга;

3) 13 статьяда:

а) 3 пунктның өченче абзацында "Җирлек сайлау комиссиясе" сүзләрен "территориаль комиссия" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктта "сайлау комиссияләре" сүзләрен "территориаль комиссия" сүзләренә алмаштырырга;

4) 14 статьяда:

а) 5 пунктта "Җирлек сайлау комиссиясе" сүзләрен "территориаль комиссия" сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 пунктта "Җирлек сайлау комиссиясе" сүзләрен "территориаль комиссия" сүзләренә алмаштырырга, "сайлау комиссиясе" сүзләрен "территориаль комиссия" сүзләренә алмаштырырга;

в) 12 пунктта "сайлау комиссиясе" сүзләрен "территориаль комиссия" сүзләренә алмаштырырга;

5) 19 статьяның 5 пунктының икенче абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1-7 һәм 9_2 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга.;

6) 35 статьяда:

а) 1 пунктның 15 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

б) 1 пунктның 32 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"32) муниципаль хокукый актларны, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру; ";

7) 42 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10.1 пунктча өстәргә:

"10.1) аның чит ил агенты статусын алуы;»;

8) 51 статьяда:

а) 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле 8 абзац белән тулыландырырга:

"- "Шәхси ярдәмче хуҗалык турында" 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала";

б) 1 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4) халыкка торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә:

- халыкны җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра; базарлар һәм ярминкәләр оештыра;

- торак законнары нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торагына һаем шартнамәләре буенча гражданнарга муниципаль торак фондыннан торак бирә;

- ял итүне оештыру һәм халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

-җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын алып баруны оештыра;

- гражданнарның су объектларына иркенле керүен тәэмин итүне дә кертеп, җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыра һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыра;

- энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә

муниципаль программаларны гамәлгә ашыра, муниципаль берәмлек чикләрендәге урыннары муниципаль торак фондын тәшкил итә торган күпфатирлы йортларга энергетик тикшерү уздыруны оештыра, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнарда каралган башка чараларны оештыра һәм үткәрә;

- ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыра һәм җирләү урыннарын карап тота;

-Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су кертүне, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыра;

-үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү турында, үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә карарлар кабул итә;

- төзекләндерү өлкәсендә аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру торган муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

в) 1 пунктның 7 пунктчасындагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

г) 3 пунктта "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон" сүзләрен "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон" сүзләренә алмаштырырга.

9)VII бүлекне һәм 55 статьяны үз көчләрен югалткан дип танырга;

10) 60 статьяның 3 пунктында "Җирлек сайлау комиссиясе" сүзләрен "территориаль комиссия" сүзләренә алмаштырырга;

11) 73 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"73 статья. Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе"

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гамәлгә куйган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар халыкка рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү булып тора:

1) тулы текстны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык ЭЛ №ФС77-60244 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт тарафыннан (Роскомнадзор) 17.12.2013 бирелгән яисә «Арча хәбәрләре» («Арчский вестник») Арча район газетасында (массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык ЭЛ № ФС77–47527 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт тарафыннан 30.11.2011 бирелгән) рәсми бастырып чыгару;

2) Арча муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру;

3) Яңа Кырлай авылы, Үзәк урамы, 3 йорт; Өчиле авылы, Тукай урамы, 73 йорт адреслары буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен түбәндәге адреслар буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары эшли: Яңа Кырлай авылы, Үзәк урамы, 3 йорт; Өчиле авылы, Тукай урамы, 73 йорт.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларга кул куелган көннән алып 7 көн эчендә халыкка җиткерелә.

5. «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга кул куелган көннән үз көченә керә.

7. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка җиткерү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) гамәлгә ашырыла торган вакытлы матбугат басмаларының, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле сайтларның домен исемнәрен һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы белешмәләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмаларының, челтәр басмаларының исемлеге «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерелә.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алганнан соң Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Яңа Кырлай авылы, Үзәк урамы, 3 йорт; Өчиле авылы, Тукай урамы, 73 йорт.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров